Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Бакырчы авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2020 ел 9 гыйнвар № 168

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

авыл җирлеге мөлкәтендә булган милек белән эш итү.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге башкарма комитетына;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын исәпкә алырга;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге Советының бюджет законнары нигезендә карар проектын эшләргә һәм тикшерүгә тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлекләр бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бакырчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Бакырчы авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Х. Вәлиев**